**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

---

**2021 елның 24 декабре** **75 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Бутыри торак пунктында гражданнар җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Бутыри торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2022 елда Лаеш муниципаль районының **Александр авыл** җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2022 елда үзара салым акчаларын 3500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Бутыри торак пунктында Садовая, Центральная, Степная, Озерная урамнарында урам юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Александр авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авылҗирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______ А.И.Каппель**

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Александр авылҗирлеге**
**Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы Ю.Г.Трифонова**